# Без бергә





# Без бергә




# Дуслык дәресе

Бу гаҗәеп вакыйга иң гади бер көзге көндә булды. Беренче сыйныф укучысы Тимур һәм аның дуслары мәктәп линейкасыннан соң ук әкият иленә эләгербез дип уйладымы икән? Юк, әлбәттә. Ләкин, гадәттәгечә, маҗаралар көтмәгән җирдә килеп чыга.








– Сезнең беренче дәресегез дуслык дәресе булачак, чөнки халыклар арасында татулык бик мөһим! – диде укытучы балаларга. – Ә аны без Дуслык залында үткәрәчәкбез.

Тимурга мәктәптә беренче көн ошады, аның тизрәк сыйныфташлары белән танышасы килде. Экскурсиянең беткәнен дә көтмичә, Тимур балалар янына килде һәм үзе белән таныштырды.





– Ә минем исемем Салика, – дип җавап бирде кызларның берсе Тимурга.

– Нинди кызык исем, – диделәр балалар, гаҗәпләнеп.

– Ул мари исеме, – дип горурланып җавап бирде Салика. – Ә синең исемең ничек?

– Йёкепи, мин – чуваш кызы. Карагыз, минем нәрсәм бар, – дип, ул сумкасыннан искиткеч матур чигешле пенал алды. – Бу безнең милли чуваш бизәге!

Тимур Кузай исемле малайның – мордвин, Чыжытның – удмурт, ә озын толымлы Машаның рус кызы икәнен белде.

– Шәп! – диде сөенеп Тимур. – Без төрлебез төрле милләттән, бер сыйныфта укыйбыз! Әйдәгез дуслашыйк!




Балалар яхшы дуслар булырга, укуда бер-берсенә ярдәм итәргә, дәресләрдән соң бергә булырга дигән ныклы карарга килделәр.

– Ә безнең укытучы кайда соң? Без экскурсиядән артта калдык бугай! – диде Тимур, як-ягына каранып.

Балалар коридор буйлап йөгерделәр, ләкин мәктәптә беренче көннәре генә булганга, бик тиз адаштылар һәм «Керергә ярамый» дип язылган ачык ишек янында туктадылар.





– Гафу итегез, Дуслык залына ничек барырга? – дип сорады Кузай.

Ләкин аңа берәү дә җавап бирмәде. Бүлмә лабораториягә охшаган иде. Аның уртасында өстәл, ә өстәлдә нидер балкып тора иде.

– Нинди матур таш... – диде Салика һәм кулын сузды.

– Тимә аңа! – дип кычкырды Тимур. Тик Салика инде ташка кагылган иде, һәм ул ал төскә кереп яна башлады.

– Сез ни эшләдегез? – диде укытучы. – Бу – Кара Ташларның берсе. Кешеләр талашканда, усал сүзләр кара ташларга әверелә. Без тикшеренү үткәрергә теләгән идек, тик хәзер сезгә шактый катлаулы сәяхәткә чыгарга туры киләчәк.





– Безгә? – дип гаҗәпләнде балалар.

– Әйе. Ташка кагылган кеше аны Зирәклек Коесына ташларга тиеш, юкса Кара Таш, көч җыеп, бар дөнья буйлап ызгыш-талаш тарата башлаячак. Сезнең төгәл өч көнегез бар!



– Безгә кая барырга соң? – диде куркуга калган Чыжыт.

Укытучы стенага кагылды, һәм анда әкиятләрнең тылсымлы дөньясына керүнең яшерен юлы пәйда булды. Тимур һәрвакыт гадәти булмаган мәктәптә укырга теләде, тик аны тылсымлы булыр дип, ул хәтта күз алдына да китермәгән иде.



– Борынгы Биләр шәһәренә барыгыз һәм ташны тылсымлы суга ташлагыз. Бары тик шулай гына тынычлыкны саклап калып була, – диде укытучы һәм кул чабып алды.

Алдагы мизгелдә балалар инде яшел аланда басып тора, ә алар каршында гаҗәеп илнең җентекләп эшләнгән картасы ята иде.



## Тынычлык һәм дуслык, ярдәм итегез!

Соңгы мизгелдә укытучы дусларга теләсә нинди бәладә ярдәм итә торган тылсымлы сүзләрне әйтергә өлгерде: «Дошманнар, чигенегез! Тынычлык һәм дуслык, ярдәм итегез!»

Тимур картаны кулына алды һәм болай диде:

– Халык риваятьләре иле. Карагыз, бу – без! Ә менә кое да.



– Монда «Чумбылат» дип язылган, – диде Салика һәм атамага кагылды. Хәрефләр көмеш төскә кереп кабынды, һәм җир астыннан тау калкып чыкты.

– Изге Чумбылат тавы! – дип кычкырып җибәрде Салика. – Безгә яшерен юл аша үтәргә кирәк!



Шул мизгелдә балалар каршында сәер башлык кигән озын буйлы кеше пәйда булды.

– Млит! – диде Салика әкрен генә. – Мари әкиятләрендәге явыз урман рухы!

– Мин шул! – диде Млит. – Ә сез кемнәр соң?

Салика, кыюлыгын җыеп:

– Без дуслар белән... саф һавада йөрибез! Зинһар өчен, җибәр безне, – диде.

– Үземнең байлыкларымны күрсәтмичә җибәрмим, – дип җавап бирде хәйләкәр Млит.

– Ышанмагыз аңа! – дип пышылдады Салика. – Аның белән барырга ярамый! Хәтереңне югалтканчы, урманда әйләндереп йөртәчәк.

– Нишләргә соң? – дип сулкылдады Йĕкепи.

– Хәйләлибез аны, – дип күз кысты Салика.



– Әйт әле, Млит, урман буйлап каңгырап йөрү күңелсез түгелме сиңа? Әйдә безнең белән Кандыр биюе биергә.

– Мин сөякләрне язып алырга каршы түгел, – дип сөенде Млит, ә үзе балаларны урманга алып китәргә уйлады.

Салика дусларына тиз генә явыз рухларның көчен ала торган «Баучык» дип аталган тылсымлы мари биюе турында сөйләде:

– Иң мөһиме – кулга-кул ныграк тотынышыгыз, ә инде мин сынатмам!

Салика тылсымлы сүзләрне әйтте: «Дошманнар, чигенегез! Тынычлык һәм дуслык, ярдәм итегез!» һәм шундук камчыга әверелде.

Балалар Млитны әйләндереп алды, тыпырдаша-тыпырдаша, сиздерми генә яшерен керү юлына үтте. Млит үзен хәйләләгәннәрен аңлап алды, һәм аның ачуы чыкты.







Млит балаларны тотып алырга теләгән иде, тик Салика-камчы аның борыны төбендә генә шартлады. Рух курыкты, чигенде, чөнки ул барыннан да ныграк камчыдан курка иде. Ә балалар Чумбылат тавына йөгереп керделәр һәм, күз ачып йомганчы, аның икенче ягына килеп чыктылар.



– Сүзләр чыннан да тылсымлы микәнни? – дип гаҗәпләнде Тимур, Салика янәдән кызга әйләнгәч.

– Димәк, тылсымлы! Бар да килеп чыкты бит. Дусларыма ярдәм итә алуыма мин шундый шат! – диде Салика, елмаеп.

«Ярый әле Салика мари әкиятләрен белә, һәм без кабат бергә», – дип уйлап куйды Тимур.



# Бердәмлектә – көч!

Тимур янә картага карады һәм:

– Язуы беткән. Бәлки, берәрсеннән сораргадыр? – диде.

– Әкрен! – дип пышылдады Кузай. – Кемдер ярдәмгә чакыра!

– Карагыз әле, монда нәрсә бар! – диде Йӗкепи, һәм балалар агачка бәйләп куелган күлмәкне күреп алды.


Могҗизалар дәвам итте, һәм агачта чынлап та күлмәк эленеп тора иде, тик гади күлмәк түгел...

– Мин сине беләм, – дип елмайды Йёкепи. – Син чуваш әкиятендәге Такылдык Күлмәк һәм бик күп сөйләшергә яратасың.



– Ай-ай! – дип елап җибәрде Күлмәк. – Балакайларым, чишегез мине, зинһар! Җилдә бөтен чигүем таушалып бетте. Ә мин сезгә юлны күрсәтәм. Сез бит монда юкка гына йөрмисез?

– Без сиңа ярдәм итәбез! – диде Йёкепи, аны кызганып. – Мин синең явыз һәм куркыныч түгел икәнеңне беләм, ә монда сине, өйгә кертмәгәнең өчен, җен баласы бәйләп куйган.



Йёкепи тылсымлы сүзләрне әйтте һәм энә белән йомгакка әверелде. Балалар күз ачып йомарга да өлгермәде, энә Күлмәк итәгенә матур чуваш бизәге чигеп тә куйды.






– Рәхмәт, игелекле балалар! – диде Такылдык Күлмәк, дусларга рәхмәтен белдереп. – Ярдәмегез өчен мин сезгә бүләк ясыйм. Бирегез монда картагызны!

Картада ашъяулыктагы кебек гаҗәеп матур бизәкләр пәйда булды. Бер генә төен дә, җеп очы да таба алмассың! Рәсеме дә ике якта да шома!

– Чуваш бизәкләре һәм чигү осталары бөтен илгә танылган! – диде Йёкепи, горурланып.



– Карагыз әле! – диде Маша. – Картадагы бизәк Йӗкепиның пеналындагы кебек үк!

– Ул кояшны аңлата, ә бу «Шыв юххи» – инеш.

– Димәк, безгә инеш буена барырга кирәк, – диде Тимур, аңлап алып.

– Ә кояш безгә аңа таба юлны күрсәтер! – дип эләктереп алды Кузай.





– Бергә без теләсә нинди көчне дә җиңәрбез һәм теләсә нинди табышмакны да чишәрбез! – дип елмайды Маша.

Балалар Такылдык Күлмәк белән саубуллашты да юлга кузгалды.

# Тылсымлы ярдәмче

Кич җитеп килә иде. Дуслар басуда, зур печән кибәне янында төн кунарга булды.

– Монда шундый җылы!

– Мин оя таптым, ә анда йомырка, – диде Кузай.

– Мөгаен, аны берәр кош калдыргандыр. Әйдәгез, эчендәге кошчык туңмасын өчен, аны җылытабыз! – дип шаулашты балалар аның тирәсендә.

Кузай төне буе ояны җылытты, ә иртән сәер хәл булды.

– Дуслар, кошчык хәзер йомыркадан чыгар, ахры! – дип сөенде Кузай.

Кабык чатнап китте һәм шундук юк булды, ә аның урынында канатлы һәм озын койрыклы сәер бер җан иясе пәйда булды.





– Хуҗам, тизрәк эш бир миңа! – дип елап җибәрде җәнлек.

– Бу бит мордва әкиятләрендәге эш рухы Куйгорож! – дип аңлап алды Кузай. – Хәзер ул безнең арттан эш сорап йөриячәк.

– Бу яхшы бит! – дип сөенде дуслар.





– Дөресен әйткәндә, Куйгорож бик үк яхшы ярдәмче түгел, – дип кисәтте Кузай. – Әгәр аңа эш бирмәсәң, ул бар нәрсәне җимерергә мөмкин. Эшне башкара алмаса гына китәчәк.

– Берәр нәрсә уйлап табарбыз, – дип күз кысты Тимур.



Балалар киң елга буена килеп чыкты.

– Куйгорож, басма сал безгә! – дип боерды Кузай.

Рух шундук эшкә тотынды, ә басма әзер булгач, янә эш сорый башлады.



– Бүтән бездә синең өчен эш юк, – диде Кузай.

– Алайса барын да җимерәм, ватам, – дип, Куйгорож койрыгы белән басмага сукты. Тимур, иелеп, Кузайның колагына нидер пышылдады.



Кузай шатланып баш какты һәм Куйгорожга:
– Әй, рух! Кырга су сибәргә кирәк! – диде, ә үзе «Дошманнар, чигенегез! Тынычлык һәм дуслык, ярдәм итегез!» дигән тылсымлы сүзләрне әйтте дә иләккә әверелде.

Куйгорож, иләкне алып, елгага таба йөгерде. Кире килде, ә иләк буш иде. Янә елга буена китте. Ә Кузай, дуслары басмадан икенче ярга чыгуга, кире малайга әйләнде.

– Эшне башкарып чыга алмадың син, рух! Үзеңә башка хуҗалар эзлә! – дип кычкырды ул Куйгорожга һәм дуслары белән бергә юлын дәвам итте.





# Бердәмлек тау күчерә

Янда дуслар булганда, атлавы да җиңел һәм күңелле. Салика, Маша һәм Йёкепи юл уңаенда хуш исле үлән һәм җиләкләр җыйды.

Балалар ял итәргә, елга буенда кайнар чәй эчеп алырга булды. Чыжыт учак өчен утын яра башлады һәм ялгыш балтасын суга төшереп җибәрде.

– Кем ул анда? Кем минем елгамны тынычсызлый? – диде кемдер, һәм елгадан су иясе килеп чыкты.

– Вумурт! Удмурт әкиятләрендәге елгалар хуҗасы, – диде Чыжыт балаларга әкрен генә. – Ул болай гына җибәрмәячәк.

– Нишләргә соң? – дип борчыла башлады дуслар.



– Төш вакытында, кояш кыздыра башлагач, ул кибәчәк, – диде Чыжыт. – Тик аны яр буенда тоткарларга кирәк. Аның игътибарын читкә юнәлтегез, ә мин сынатмам!

Чыжыт тылсымлы сүзләр әйтте һәм пәрәпәчкә – зур удмурт пәрәмәченә әверелде. Вумурт пәрәпәчне күрде дә иреннәрен ялап куйды.

– Сыйлан, Вумурт! – диде балалар.





Вумурт пәрәпәч ашады, ә балалар аның янында җырлар җырлап, әкиятләр сөйләп утырды. Ә кояш һаман югарырак күтәрелә барды. Вумурт пәрәпәчне ашап бетерергә дә өлгермәде, кояш нурлары астында кипте һәм кечкенә балыкка охшап калды. Тимур аны, койрыгыннан тотып, кире елгага ыргытты.



– Ашатканыгыз һәм үлемнән коткарганыгыз өчен рәхмәт, – дип, Вумурт судан килеп чыкты. – Ә менә сезнең балтагыз, алыгыз!

Пәрәпәч валчыгы сикерде һәм янә малайга әверелде.

– Чыжыт! Дус! Без яңадан бергә! – дип сөенде балалар. – Бер җирең дә авыртмадымы?

– Юк, – дип көлә башлады кызарган Чыжыт. – Бары тик ул миннән валчык та калдырмас дип кенә курыктым.

Балалар берьюлы көлеп җибәрде һәм тагын юлга кузгалды.



# Куркыныч төн

Дуслар караңгы куе урманга килеп җитте. Кара Таш яктырганнан яктыра барды – балаларның Зирәклек Коесына барып җитеп, Җирдә ызгыш-талашка юл куймау өчен вакытлары бик аз калды.

– Куркыныч монда, – диде Маша, як-ягына каранып.



– Карагыз әле, йорт! – диде Чыжыт, сөенеп, һәм алга йөгерде.

Чыннан да, аланда агач йорт тора иде. Ишек шыгырдап ачылды, һәм бусагада бер карчык пәйда булды.

– Керегез, керегез, кадерле кунаклар! Нәкъ кичке ашка килеп җиттегез, – диде ул.

Тамаклары ачкан дуслар карчыкның чакыруына куанды.



Кичке аш вакытында дуслар Зирәклек Коесына барулары турында сөйләде һәм хуҗабикәгә Кара Ташны күрсәтте. Аның чып-чын Убырлы карчык булуы дусларның башына да килмәде.

– Юлыгыз якын түгел. Миндә кунарга калыгыз, – дип тәкъдим итте Убырлы карчык.

Балалар шундый арыган иде: шундук йокыга киттеләр. Маша гына йоклый алмады.

Кинәт Маша йорт хуҗасының акрын гына Тимурдан таш салынган төенчекне тартып алуын күрде.

– Нишлисез сез?! – дип кычкырып җибәрде Маша. Ә сихерченең усал йөзен күргәч, кинәт аңлап алды. – Сез... Сез – Убырлы карчык!





Дуслар шундук караватларыннан сикереп торды.

– Әйе! Ә таш хәзер минеке! – дип көлеп җибәрде Убырлы карчык һәм, балаларны имән терәк белән бикләп куяр өчен, ишеккә ташланды.

Шул ук мизгелдә Маша тылсымлы сүзләрне пышылдады һәм үзеннән-үзе уйный торган... гөсләгә әверелде! Гөслә уйный башлауга, барысы да биергә тотынды.





Убырлы карчык биеде-биеде дә хәлсезләнеп егылды. Шул ук мизгелдә Маша кире кызга әверелде. Дуслар, Кара Ташны алып, өйдән чыгып йөгерде. Алда аларны яңа маҗаралар көтә, тик иң мөһиме, балалар янә бергә иде...



# Без бергә!

Бераз вакыт барганнан соң, дуслар әкияти бер авылга килеп җитте. Бар җирдә уен-көлке, барысы да җырлый, уйный, бии – Сабантуй бәйрәме бара!



Бик матур мәйданда Редис-батыр Шалкан белән көрәшә, ә баганага итекләрне алырга йомры Бәрәңге менгән! Менә сиңа мә!

– Әй, борчаклар, ник боегып киттегез? – дип эндәште балаларга зур суганга охшаган карт. – Әллә уңышның күзен бәйрәм иткәнен оныттыгызмы?

– Күңел ачу кайгысы юк әле бездә, Суган бабай, – диде Тимур.





– Безгә дуслар белән тизрәк тылсымлы Биләр каласына барып җитәргә кирәк, нибары ике сәгать вакыт калды.

– Ә анда бару сезгә ник кирәк булды соң? – дип кызыксынды мәрхәмәтле Суган бабай.



– Әгәр Кара Ташны Зирәклек Коесына ташламасак, бөтен дөньяда ызгыш-талаш башланачак, һәм бәйрәмнәр бүтән булмаячак, – диде Тимур моңсу гына.

– Ай-яй-яй! Ай-яй-яй, – диде Суган бабай, бик нык кайгырып.

Тимурның сүзләре аның күңеленә шулкадәр борчу салды, хәтта дусларның да борыннары әчетергә, күз яшьләре агарга тотынды. Шуңа суган бит инде ул.

– Суган бабай, зинһар өчен, ярдәм ит безгә! Без синең мәрхәмәтле һәм зирәк икәнеңне беләбез, – диде дуслар.



– Яхшылык эшләргә теләвегезне күрәм. Мин сезгә ярдәм итәм. Үземнең иң яхшы арбамны бирәм. Тик минем атым юк. Әмма, мәкальдә әйтелгәнчә, кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле. Берәр нәрсә уйлап табарсыз, – диде Суган бабай, балаларга күз кысып.



Балалар Суган бабайга рәхмәт әйтте һәм уйга калды: арбаны атсыз ничек кузгатырга соң?

– Мин нишләргә кирәген беләм! – дип кычкырып җибәрде Тимур. – Кызлар, арбага утырыгыз. Кузай һәм Чыжыт, тәртәләрне тотыгыз, ә мин сынатмам!





Тимур тылсымлы сүзләрне әйтте дә татар халык әкиятендәге иске башмакларга әверелде. Аларны киюгә, күз ачып йомганчы, кирәкле урында буласың.

Кузай белән Чыжыт берәр башмак киде һәм бик тиз арада могҗизалар тулы Биләргә килеп җитте.



Дуслар башмакларын салды, карасалар, алар ышкылып тишелеп беткән икән. Йӗкепи энә белән җеп алды да барлык тишекләрне ямап куйды. Һәм Тимур янә малайга әверелде. Дуслар бик сөенде! Нык итеп кочаклашты.





– Булдырдың, Тимур! Афәрин!

– Без бергә! Барыбыз да булдырдык! – дип куанды Тимур.



Дуслар Зирәклек Коесы янына килде, кулга-кул тотыныштылар һәм:

– Дошманнар, чигенегез! Тынычлык һәм дуслык, ярдәм итегез! – дип кычкырды.

Кара Таш әкрен генә төшеп китте, коедагы су быгырдап кайный башлады, кара төскә керде, әмма шундук чистарды һәм ялтырый башлады. Ызгыш-талаш юк ителде!

Шул ук мизгелдә мәрмәр идән кинәт ачылып китте һәм балаларның аяк астында баскыч пәйда булды. Дуслар, кулга-кул тотынышып, әкрен генә аска төшә башлады һәм янә... мәктәптә пәйда булды.





– Әй, борчаклар, сез киемнәрегезне гардеробтан алмадыгызмы? Мин аларны кичкә кадәр сакларга тиешме? – дип дәште аларга мәктәп каравылчысы.

Балалар бер-берсенә карашып алдылар һәм берьюлы көлеп җибәрделәр, чөнки ул Суган бабайга бик нык охшаган иде.



Кинәт дуслар укытучыларын күреп алды.

– Кара Таш Зирәклек Коесында! Без барын да башкарып чыктык! Тылсымлы сүзләр өчен рәхмәт! – диде балалар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә.

– Афәрин! – дип елмайды укытучы. – Әмма юлдагы куркынычларны җиңәргә сезгә тылсымлы сүзләр түгел, ә ДУСЛЫК ярдәм итте!

– Дөрес, мәкальдә ничек әйтелә әле? – дип күз кысты каравылчы бабай. – Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле!



– Дөрес! Дуслык чын могҗизалар тудырырга ярдәм итә! – дип елмайды Тимур.

– Безнең көч – дуслыкта һәм бердәмлектә! – дип эләктереп алды балалар.

– Без һәрвакыт бергә булачакбыз!



ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ
В РЕСПУБЛИКЕ
ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

# ЭЧТӘЛЕК
# СОДЕРЖАНИЕ


ДУСЛЫК ДӘРЕСЕ ........ 4
УРОК ДРУЖБЫ ........ 5

ТЫНЫЧЛЫК ҺӘМ ДУСЛЫК, ЯРДӘМ ИТЕГЕЗ! ........ 18
МИР И ДРУЖБА, ПОМОГИТЕ! ........ 19

БЕРДӘМЛЕКТӘ – КӨЧ! ........ 30
ВМЕСТЕ МЫ СИЛА! ........ 31

ТЫЛСЫМЛЫ ЯРДӘМЧЕ ........ 42
ВОЛШЕБНЫЙ ПОМОЩНИК ........ 42

БЕРДӘМЛЕК ТАУ КҮЧЕРӘ ........ 54
ОДИН ЗА ВСЕХ ........ 55

КУРКЫНЫЧ ТӨН ........ 64
ОПАСНАЯ НОЧЬ ........ 65

БЕЗ БЕРГӘ! ........ 74
МЫ ВМЕСТЕ! ........ 75

# Без берга     Мы вместе


**Художественно-просветительское издание для детей на татарском и русском языках**

Автор проекта
**Лейла Фазлеева**

Руководитель проекта
**Азат Ганиев**

Главный редактор
**Гульнара Головина**

Литературная редакция:
**Расима Шамсутдинова, Алсу Низамеева, Зухра Фасхиева, Фарида Ахметзянова, Инна Макарова, Фаниса Макарова**

Художники-иллюстраторы:
**Елизавета Семенская, Юлия Артемьева, Полина Михайлова, Дарья Михайлова, Жанна Захарян**

Дизайн и графическая вёрстка
**Дмитрий Гиацинтов**

Музыкальная редакция:
**Мария Сергеева, Рафаэль Бахтиозин**

Руководитель IT отдела
**Дамир Бариев**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Методисты:
**Эльмира Тахавиева, Лейсан Зиннатуллина, Татьяна Курамшина**

Консультанты:
**Расима Шамсутдинова, Ирек Шарипов**

Фактологические материалы предоставлены
**Ассамблеей народов Татарстана и Домом Дружбы народов Татарстана**

Эксперты культурно-этнографического контента:
**Людмила Мусихина**, заместитель председателя Совета РОО «Национально-культурная автономия марийцев Республики Татарстан», председатель МОО «Национально-культурная автономия марийцев Республики Татарстан»

**Сильвия Чаркина**, заместитель председателя РОО «Чувашская национально-культурная автономия в Республике Татарстан»

**Наталья Сабитова**, руководитель РОО «Национально-культурная автономия мордвы Республики Татарстан»

**Павел Александров**, заведующий отделом развития народного творчества ГБУ «Ресурсный центр внедрения инноваций и сохранения традиций в сфере культуры Республики Татарстан»

**Любовь Тукаева**, руководитель отдела этнокультурной деятельности Дома Дружбы народов Татарстана

**Татарское детское издательство**
Редакция Гульнары Головиной

420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Отпечатано в типографии ООО «ЛД-ПРИНТ»
196643, Россия, Санкт-Петербург, Колпинский р-н, пос. Сапёрный,
ш. Петрозаводское, д. 61, стр. 6. Тел. (812) 462-83-83, e-mail: office@ldprint.ru
Подписано в печать 20.06.2022, формат 210x270 1/16
Тираж 63 000 экз. Заказ № 24570

Татар һәм рус телләрендә
балалар өчен әдәби-агарту басмасы

# Без бергә

www.без-берге.рф



ISBN 978-5-6046008-1-8

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ
www.tdpress.ru